КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2026 ел, 25 февраль

г.Казань

№ 134

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 29 сентябрь, 778 нче карары белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү проектларын комплекслы озата баруга һәм аларга ярдәм итүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү проектларын комплекслы озата баруга һәм аларга ярдәм итүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 29 сентябрь, 778 нче карары белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү проектларын комплекслы озата баруга һәм аларга ярдәм итүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктка «, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә.» сүзләрен өстәргә;

30 пунктның беренче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

33 пунктта:

беренче абзацта «субсидия тиеш» сүзләрен «субсидия акчалары тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «субсидия тиеш» сүзләрен «субсидия акчалары тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацлары нигезендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару өчен нигез булган хәлләр ачыкланган көннән 30 календарь көннән артмаган срокта субсидия алучыга таләп алынган көннән 10 календарь көн эчендә субсидия акчасын кире кайтару турында таләп җибәрү юлы белән субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә.»;

35 пунктта «субсидияне кире кайтарудан» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтарудан» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин